**КАРАР**

**2022 елның 9 ноябреннән** **№16/3**

**Кукмара муниципаль районының Өркеш авылы Өркеш авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Өркеш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2022 елның 23 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районының Өркешавыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Өркеш авылы балалар спорт мәйданчыгында гражданнар җыенын үткәрергә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "2023 елда Кукмара муниципаль районының Өркеш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ яшьтән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы Сез:
- 1 төркем инвалидлар;
- көндезге уку формасы буенча укучылар һәм студентлар (курсантлар);
-18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр;
- 18 яшькә кадәр бала тәрбияләүче ялгыз әниләр;
-80 яшь һәм аннан өлкәнрәк затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары»
алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:
- Подгорная урамындагы юлларга вак таш салу (сатып алу, ташу, вак таш салу,), проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру;
- җәйге вакытта территорияне тайпу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
- кышкы вакытта территорияне кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, запас частьләр, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү)
- Өркеш авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;
- Подгорная урамы, Өркеш авылы буенча артезиан скважиналарын куллануга лицензия алу өчен документлар пакетын һәм лаборатор тикшеренүләр әзерләү буенча чаралар үткәрү (2 скважина);
- Подгорная урамында, Өркеш авылында янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру;
- урам утлары, яктырткычлар, Өркеш авылында махсус җиһазлар сатып алу, энергия саклаучы лампалар урнаштыру.
- торак пунктны төзекләндерү (балалар мәйданчыгы тирәсендә койма алу һәм урнаштыру);
- урам-юл челтәрен һәм Өркеш авылы ишегалды юлларын ремонтлау-торгызу эшләре (проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру);
"КАРШЫ" ӨЧЕН.
3. Җыен оештыручы итеп Өркеш авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.
4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә http://kukmor.tatar.ru.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Өркеш авыл җирлеге башлыгы: А.Ш.Әгъләмова

ОГРН 1021607...870
ИНН 1623001822